**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«29» 11 2019 ел Яр Чаллы № 5245

«ТР Тукай муниципаль районы Бәтке урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «ТР Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 30 статьясы 21 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль мәгариф оешмалары хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 10 январендәге 4 номерлы карары нигезендә

**К А Р А Р  Б И Р Ә:**

1. «ТР Тукай муниципаль районы Бәтке урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә бәяләрне кушымта нигезендә расларга.
2. Хезмәтләр бәясен исәпләүне бәя исәбе анализы нигезендә расларга.
3. Карарның гамәлдә булуы 2019 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында урнаштырырга.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы А.Х. Мөхәммәтҗановага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Г. Авзалов